# ГӨЛЧӘЧӘКЛӘР ИЛЕНДӘ КАРА БОЛЫТ

## Имеш-мимешләр

Болгариянең ниндидер сөйкемле сөяге бар, ахры. Югыйсә Мәскәү матбугатында көн саен аңа багышланган дистәләрчә мәкалә басылып чыгар идеме? Халкы миллиардтан ашкан Кытай, мәйданы ягыннан Кытайга тиң Канада, тарихи багланышларыбыз гасырларга, уртак чигебез йөзләрчә чакрымга сузылган күршебез Төркия бар — алар турында атнага, айга бер хәбәр басылмый. Ә Болгария турында укып кына өлгер! Вакытлы матбугат, радио-телевидение, кино туктаусыз шушы илне яктырта, һәрвакыт уңышларын, казанышларын гына күрсәтә. Бу җәһәттән, татар гәзитләре дә калышмый. Бөтен Болгарияне каплаган җиләк-җимеш бакчалары, гөлчәчәк кырлары, Кара диңгез буена салынган гүзәл ял йортлары — болары инде буш сүз дә түгел. Компотлары, җимеш сутлары, хушбуйлары безгә дә килеп җитә. Рәсәй туристларының яртысы диярлек Болгариягә барып сәламәтлеген ныгыта. Илгизәрләрнең күпчелеге беравыздан:

— Безне иң җылы кабул итүче ил — Болгария, — дип белдерә.

— Болгария СССРның уналтынчы республикасы кебек. Ул безнең ил составына керергә әллә кайчаннан бирле тели икән, — дип өстәүчеләр дә байтак иде.

Бәйсез, иректә яшәү — һәр милләтнең татлы хыялы. Бәйсезлеген югалтмау өчен, халыклар канкойгыч, фаҗигале сугышлар алып барудан да тайчанмыйлар. Ә болгарлар үзләре теләп ирекләрен чикләргә омтылсын, имеш. Дөрес, алар, — урыслар кебек үк, славяннар. Аларның славянлык хисен көчәйтүдә, бәйсез дәүләтен тергезүдә нәкъ менә урыс патшалары төп рольне уйный: 1877 — 1878 елларда болгарларны Төркия кулы астыннан чыгару сугышларында Русиянең бер ярым миллионлы гаскәре катнашса, көрәшкә күтәрелгән җирле халык саны ун меңнән дә артмый. Әлбәттә, урыс

патшалары Балкандагы славян кан кардәшләрен азат итүне байрак сыман күтәрсә дә, аларның төп максатлары Госманлы империясен гомумән буйсындыру, Төркиянең Босфор һәм Дарданелл бугазларын кулга төшереп, җылы диңгезләргә юл ачу, яңа җирләр басып алу, талауларга әзерләнү була. Менә шуңа күрә ул 1877—1878 елларда Балкан фронтындагы ике йөз меңле төрек гаскәренә каршы җиде-сигез тапкыр күбрәк санлы хәрби көч китерә!

«Русия дәүләтен дөнья мәмләкәтенә әйләндерер өчен, аның башкаласын Азия һәм Европа хәзинәләренең ачкычы булган Истанбулга күчерү шарт, — ди патша Пётр I 1725 елда язган васыятендә. — Кичекми һәм ялгышмый эш итеп, Истанбулның көнбатыш җирләренә ия булу кирәк. Шөбһәсез ки, Истанбулга ия булган патша дөньяда илаһи патша булачак. Бу максатка ирешү өчен, Төркия белән Иран арасына дошманлык орлыкларын даими чәчәргә, ызгыш һәм сугыш чыгарырга кирәк. Бу эш өчен сөнни һәм шигый мәзһәпләре арасындагы каршылыклар — иң хәлиткеч корал һәм җиңелмәс гаскәрдер. Русиянең үтеп керүен Азиягә җәю өчен, сөнни-шигый каршылыклары — иң яхшы чара. Төркия белән Иран дәүләтләре арасындагы тотрыклы татулыкны шундый итеп бозу кирәк ки, алар бер-берсе белән һичбер заман аңлаша алмасыннар. Һәм Иран, һәм дә Төркиянең Аурупа халыклары белән бәйләныш ясавына мөмкинлек бирмәскә кирәк...

Матди ихтыяҗларыбыз даирәсе булган Төркиянең эшен бетергәннән соң, Иранны ансат кына юк итү һәм аның «башын кисү» мөмкиндер... Аннан соң Һиндстанга күз атарга. Ул мәмләкәт — гаять бөек һәм киң сәүдә мәйданыдыр... Һиндстанның ачкычы — Төркиянең башкаласыдыр... Төркияне Аурупадан аеру һәм бу гамәлдән Австриягә файда тәэмин итү хәерле. Бу эштә ике юл бар: «...берсе — Австриягә Төркия җирләреннән соңыннан аны кире тартып алу ансат булырлык бер өлеш кисеп бирү».

Бу васыятьне комсыз бер илбасар язганлыгын, шуннан соң Русия, аның дистәләрчә миллионлы халкы куәте соңгы дәвергә кадәр югарыдагы теләкләрне һәм бүтән басып алуларны башкарырга юнәлтүен, талау сугышларының миллионнарча кеше гомерен кисүен, күпләргә коллык, бәхетсезлек алып килүен, әмма бу басып алуларның урыс халкына да барыбер бәхет китермәвен тарихи үткәнебез бик ачык күрсәтте — Русиянең варисы СССР хәзер матди һәм рухи яктан артта калган илләр исәбендә. Чөнки халыкның тотрыклы, җитеш, хөр тормышы аның үз сәләтен, көчен

җитештерүчән хезмәткә, әхлаклы көнкүрешкә биргәндә генә җайга салына. Ләкин Русиядә моны аңлау озакка сузылды, кайберәүләр исә әле һаман да империячел һәм колонизаторлык амбицияләреннән котыла алмыйлар... Хәзер Болгария белән СССРның сәяси корылышы, хуҗалык итү рәвеше бердәй. Урыс һәм болгар телләре үзара тылмачсыз аңлашырлык дәрәҗәдә якын. Шулай да... бәйсезлекне корбан итәргә теләү аңлашылмый. Икең ике мөстәкыйль дәүләт булып яшәгәндә дә, дуслыкны һәм кардәшлекне сакларга, хезмәттәшлекне дәвам итәргә мөмкин ич.

Болгария турында бүтән имеш-мимешләр дә ишетелеп тора. Шуларның кайберсе милли мәсьәләгә кагыла. Мәгълүм ки, Дунай тамагында, Византиянең төньягында борын-борыннан төрле-төрле кабиләләр, халыклар яшәгән, аларның дәвамнары безнең көннәргә дә килеп җиткән. 1956 елгы исәп буенча, Болгариядә бер миллион чамасы төрек, алты мең татар, шактый санда гагауз, чегән, албан һәм бүтән милләт вәкилләре дә яши иде. Аларның саны шактый кимetelеп күрсәтелүе хакында да сүз күп йөрде. Әлеге азчылык милләтләр өчен махсус мәгариф һәм мәдәният учаклары ачылуын да беләбез. Мисалга, Разград, Шумен, Кырҗалы шәһәрләрендә дәүләт төрек театрлары корылуын, алар хозурында вокаль-инструменталь ансамбльләр дә оештырылуын, бу мәдәни көчләрнең ил буйлап гастрольдә йөрүе түрк телендә сөйләшүчеләргә чын бәйрәм алып килүен ишетеп тә, укып та беләбез. Болгарстандагы түрк халыклары тормышы белән танышып торыр өчен, мин үзем дә Софиядә төрекчә чыгарылган китапларны һәм «Йени Һәят» («Яңа хәят») журналын алдырып тордым. Әмма андый басмаларның килүе сиксәненче еллар башында өзелде. Болгариядә азчылык милләтләрне болгарлаштыру, мөселманнарны чукындыру башлануы хакында хәбәрләр таралды. Барлык милләтләрнең тиңлеген игълан иткән марксизм тәгълиматы нигезендә социализм төзүче илдә СССРны да уздырган мондый кискен башбаштаклык канат җәюенә ышану мөмкин түгел иде. Әмма имеш-мимешләрнең уйдырма гына түгеллеген раслаучы шаһитлар белән дә очрашырга туры килде. Шуларның берсе, Болгариядә булып кайткан таныш врачыбыз:

— Төрки халыкларның тизрәк үрчүе Болгария җитәкчеләрен пошаманга салган икән, — диде. — Шунлыктан болгар врачлары бала табарга кергән төрек-татар хатыннарына, йөккә бүтән узмасыннар өчен, укол кадый башлаганнар. Төрек врачлары моңа каршылык күрсәткәч, аларның яртысын София шифаханәләрендә эштән куып чыгарган-

нар. Хәзер төрек-татарлардан белгечләр әзерләү бик нык кимегән, милли мәктәпләре ябылган. Рәсми кунак рәвешендә татар авылына алып барганнар иде, СССРдан килгән доктор икәнлегемне һәм милләтемне ачыклагач, миңа йөзләгән кеше күренергә омтылды. Чирлеләр болгар докторларына ышанмый, алар «дәвалавы»ннан саклана икән.

1981 елның көзендә Бохарадагы дустыбыз Ирек Кәлимуллин өендә без бер дә көтмәгәндә Болгария гражданнары, ирле-хатынлы Стоян белән Лилианага юлыктык. «Сез — Дунай болгарлары, без — Идел болгарлары, ата-бабаларыбыз да, борынгы телебез-мәдәниятебез дә уртак безнең. Гасырлар агышында сез туган түрк телегезне югалткансыз, әмма исемегезне саклап калгансыз. Без исә исемебезне югалтканбыз, әмма телебезне бүгенгә кадәр яшәтеп киләбез. Шуңа күрә кардәшлегебезне, дуслыгыбызны ныгытыр һәм үстерер өчен тырышырга кирәк. Туганлыгыбызны яңартыр өчен, җирлегебез киң!» — дип сүз башладым.

Стоян Үзбәкстанда газ чыгару эшенә вакытлыча ялланган, Лилиана исә шундый ук максат белән монда килгән Болгария гражданнарының балаларына болгар теле һәм әдәбияты укыта башлаган икән. Дунай буеннан меңнәрчә чакрым ераклыктагы Караком чүлендә йөз егерме балалы болгар мәктәбенә нигез салынган! Башыма яшен тизлегендә килгән беренче уй республикабыз башкаласы Казанда, ярты миллионга якын татар яшәгән җирдә, милли мәктәпләрнең тәмам юкка чыгуы турында булды. Үзбәкстанга күчеп килгән украиннар саны болгарлардан йөзләрчә мәртәбә күбрәк, әмма монда украин теле һәм әдәбияты бөтенләй укытылмый, милли мәктәпләр Украинаның үзендә дә бик әз калган, диләр. СССРга кушылса, болгар халкы шундый хәлгә төшмәс микән? Алар украиннардан азрак санлы, тел, гореф-гадәт, холык-фигыль ягыннан да охшашлар, бер үк шартларга эләккәч, кан кардәшләре юлыннан китмәсләрме? Ниһаять, Болгариянең СССРга кушылырга атлыгып торуы, чыннан да, хакмы икән? Бу сорауны мин яңа танышларыма да бирдем.

Каршыбыздагы диванда аякларын бер-берсенә атландырып куеп, ирләр шикелле, зәңгәр төтен боҗралары очырып утыручы Лилиана, кулындагы папиросының көлен каккалап, кыска итәген озын тырнаклары белән чеметеп кенә тотып, шәрә тез башларын каплагандай хәрәкәт ясады һәм, иренә игътибар да итмәстән (гомумән, ул үзен тракторчы иренә караганда бу мәсьәләдә әзерлеклерәк саный иде, ахрысы), ышанычлы төстә:

— Беләсезме, без элек Мәскәүгә, Ленинградка барып, патша сарайларын, мәшһүр музейларны, театрларны тамаша итеп, рестораннарда сыйланып, ял итеп йөргәндә, СССРның шундый бай культуралы булуына, монда үз телебездә кыенлыксыз аңлаша алуыбызга шатлана, урысларга кардәшлегебез белән горурлана идек, — дип сүз башлады. — Менә шул чакларда: «Без бергә кушылып яшәсәк, үзебезне югары мәдәният белән ешрак, ансатрак сугара алыр идек», — дип уйладык. Бохарага поезд белән килгәндә, аннары монда яши башлагач, без бөтенләй икенче СССР белән очраштык. Таң калдык: тәртип, затлы, мул тормыш Мәскәү белән Ленинградта гына икән, бүтән тарафларда — хуҗасызлык, фәкыйрьлек, пычраклык, артта калганлык! Юу-у-ук, без үзбаш, аерым гына көн итик инде.

Болгария коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының 1963 һәм 1973 елгы пленумнарында Болгария Халык Республикасын СССРга кушу турында карар кабул ителүе чыннан да хак — бу турыда «Известия» (18.VIII.1990) гәзите дә язды. Шунысы гына серле: нәрсә этәрде икән аларны моңа? Болгариянең халыкара базарда көндәшлек тота алмаслык товарларын шактый кыйммәт бәядән сатып алуыбызмы, үз нефть-газыбызны һәм бүтән чималларыбызны Болгариягә халыкара бәянең чиреге исәбеннән бирүебезме? Хәерне мул тамызуыбызмы? Болгария авыл хуҗалыгы барыбер СССР өчен эшли, дип, шуны тагын да алга җибәрер өчен, кардәш илгә ел саен җан башына 900 сум өстәмә акча биреп бардык. Татарстанда җан башына 220 сум гына бюджет тотылганда, күрше илгә астрономик сандагы ярдәм бирелүе гаҗәпкә калдырырлык түгелме? Бәлки, ул акчаны (татар нефте һәм газыннан килгән керем!) Татарстанда сарыф итсәк, бездә юллар, терлекчелек корылмалары төзелер, авыл хуҗалыгы машиналары күбрәк җитештерелер, алдынгы технология әллә кайчан тормышка үтеп керер иде. Юк шул, безгә, кыйммәтрәккә төшсә дә, дуслар кадерлерәк, аларны асрауга очкан миллиардлар исраф санала алмый икән. Таза хәлле, юмарт күңелле «өлкән туган» ролен уйнауның заманында партия-дәүләт җитәкчеләребезгә бик тә ошаганлыгын беләбез. Шундый терәгең барында, нигә әле, бәйсез ил булам дип, төрле сәяси, икътисади эшләрне үзбаш йөртеп мәшәкатьләнергә? СССРның атом һәм ракета коралы түшәме астында кайбер милли мәсьәләләрне дә курыкмыйча хәл итәргә, халыкара җәмәгатьчелек басымына төчкереп тә карамый, кеше хокукларын нигә бозмаска, куәтле «өлкән туган»ның сөеклесе булып, нигә тәкәбберләнмәскә?